ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты каршындагы Эксперт советы составы турында” 2016 елның 4 февралендәге 1043-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты каршындагы Эксперт советы составы турында” 2016 елның 4 февралендәге 1043-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты каршындагы Эксперт советы (алга таба – Эксперт советы) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Эксперт советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Ногманова Людмила Николаевнаны – “ТИСБИ” идарә университеты” югары белем бирү учреждениесе ректоры (килешү буенча);

Кадыйров Тимур Рәфкать улын – Иҗтимагый яшьләр палатасының мәгариф, мәдәният һәм патриотик тәрбия комиссиясе рәисе, “Татарстан халыкларының Яшьләр Ассамблеясе” региональ иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча);

2) Сираева Наилә Мөҗаһит кызы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “ Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты

Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге баш киңәшчесе, Эксперт советының җаваплы секретаре".

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2017 елның 13 сентябре
№ 1913-V ДС